ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**02.12.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2309**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 24 ноябрендәге «2020-2025 елларга Зеленодольск муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2241 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль Закон, 2007 елның 4 декабрендәге «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 329-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы халкының һәрьяклап үсеше, физик яктан камилләшү һәм сәламәтлеген ныгыту өчен шартлар тудыру максатында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 24 ноябрендәге «2020-2025 елларга Зеленодольск муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2241 нче карарында «Муниципаль программа нәтиҗәләрен бәяләү максатлары, бурычлары, индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау» бүлегенең 4 пунктын «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау»ны яңа редакциядә расларга: (Кушымта).
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге начальнигына йөкләргә.

Җитәкче И. Р. Ганиев

Кушымта
Татарстан Республикасы
Зеленодоль муниципаль районы Башкарма
комитеты карары буенча
02.12.2020 №2309

| 4. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына финанслау | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары, инвентарь һәм экипировка сатып алу | РТБ | ел дәвамында | 1 139 400,00 | 1 139 400,00 | 0 | 0 | 0 | 0 | ТР ЗМР БК СБ | Спорт инвентаре, җиһазлар һәм экипировканы яхшырту һәм яңарту |
| Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының яшь белгечләренә түләүләр | РТБ | ел дәвамында | 95 500,00 | 95 500,00 | 0 | 0 | 0 | 0 | ТР ЗМР БК СБ | Матди ярдәм |
| Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчыларга-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алган нәтиҗәләре өчен түләүләр | РТБ | ел дәвамында | 2 580 000,00 | 2 580 000,00 | 0 | 0 | 0 | 0 | ТР ЗМР БК СБ | Матди ярдәм |
| Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура | РТБ | ел дәвамында | 151 300, 00 | 151 300, 00 | 0 | 0 | 0 | 0 | ТР ЗМР «Ледокол» СМ» МАУ | Спорт чаралары санын, спорт чараларында |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| спорт оешмалары командаларының хоккей буенча Татарстан Республикасы Чемпионатында, хоккей буенча Россия Федерациясе Чемпионатында спорт әзерлеге һәм катнашуы программаларын гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | катнашучы халык санын арттыру |
| Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә үсеш өчен шартлар тәэмин итүгә, физик культураны, массакүләм спортны үстерүгә, модульле чаңгы базасын оператив идарәгә тапшыруга бәйле рәвештә муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итү күләмен арттыру өчен рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыруга һәм уздыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыру | РТБ | ел дәвамында | 496 340,00 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | ТР ЗМР «Васильево штп 2 нче СМ»МБУ | Яңа спорт объектын финанслашу |
| | МБ | ел дәвамында | 5 013,54 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | ТР ЗМР «Васильево штп 2 нче СМ»МБУ | Яңа спорт объектын финанслашу |
| Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә физик культура, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми | РТБ | ел дәвамында | 960 000,00 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | ТР ЗМР БК СБ | Аутсорсинг: спорт учреждениеләрендә шөгыльләнүче спортчыларны |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга, муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан спорт әзерлеге буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль йөкләмәне финанс ягыннан тәэмин итү максатларында, әлеге учреждениеләрдә шөгыльләнүче спортчыларны ташу буенча хезмәтләр аутсорсингка бәйле чыгымнар өлешендә гамәлгә ашыру. | | | | | | | | | | ташу хезмәте |